ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 август, 2019 ел № 32/6

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар планы чорына бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары турында

2003 елның 06 нчы октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28 маддәсенә, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 19, 28 маддәләренә, Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге 34/8 санлы Карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезнамәгә таянып,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү көнен 2019 елның 11 ноябренә, үткәрү вакытын 14:00 сәгатькә тәгаенләргә, җәмәгать тыңлаулары үткәрү урыны итеп Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында (Х.Туфан проспекты, 23 йорт) 400 нче залны билгеләргә.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе составын кушымтага нигезләнеп расларга.

3. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
32/6 Карарына
кушымта
01 август, 2019 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планы чорына бюджет проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Сәгыйдуллина Ирина Алексеевна | – комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы; |
| комиссия әгъзалары: | |
| Архипов Евгений Юрьевич | – Шәһәр Советы депутаты, Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясе рәисе; |
| Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | – Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы; |
| Галиева Ләйсән Ринат кызы | Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлеге башлыгы; |
| Гыйлаҗева Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | – Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы; |
| Туктарова Венера Надир кызы | – Шәһәр Советы депутаты, Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясе рәисе; |
| Хәбибрахманова Эльвира Марс кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе финанс ресурсларын планлаштыру, анализлау һәм фаразлау бүлеге башлыгы; |

| | |
|---|---|
| Хамаева Гөлназ Гарифулла кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары; |
| Шакирова Ләйсән Әзһәм кызы | – Башкарма комитетның финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы. |